ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**28.08.2025**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2318**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елда Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмалары укучыларын кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру турында» 2024 елның 14 ноябрендәге 4300 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның балanслы кайнар ризык белән туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү, балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 21 апрелендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирелә торган уку-укыту программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм аның белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирелә торган уку-укыту программалары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән туклануының уртача бәясен раслау турында» 2024 елның 12 сентябрендәге 777 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 253 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 16 сентябрендәге 789 номерлы карары белән расланган «2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү уку-укыту программалары буенча белем алучыларны туклandыруны тәэмин итү бәясе нормативына үзгәреш кертү хакында» 2025 елның 27 маендагы 362 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елда Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмалары укучыларын кайнар ризык белән белән

тәэмин итүне оештыру турында» 2024 елның 14 ноябрендәге 4300 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2025 елның 01 сентябреннән Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүче укучылары өчен һәр уку көненә  74 сум 77 тиен күләмендә түләүсез кайнар ризык тәэмин итүне оештырырга».

1.2 карарның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2025 елның 01 сентябреннән Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүче укучыларына кайнар ризык тәэмин итү өчен Зеленодольск муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен һәр уку көненә 10 сум 30 тиен итеп  билгеләргә».

2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

3. Бу карар 2025 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе башлыгы -  җитәкче урынбасары Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин